**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Клубная, д.1а, село Кутема, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Клуб урамы, 1а йорты, Күтәмә авылы, 423112

тел.+7(84396) 4-30-88, email: Kut.Cmn2@tatar.ru

---

№ 9 | 21 август 2023 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координацион яки киңәшмә органнарын булдыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 26 октябрендәге № 13 Күтәмә авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге № 209-ФЗ Федераль законның 13 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законына, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 26 октябрендәге № 13 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координацион яки киңәшмә органнарын булдыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 6 нчы пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «6. Координацион яки киңәшмә органы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан төзелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (Pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Күтәмә авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Н.Г. Сабиров